**СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.40,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзәк урам, 40
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

“15” декабрь 2018 нче ел №47-116

“Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 4 нче сентябрендәге “Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында” 43-102 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”

2003 нче елның 6 нчы октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФК номерлы Федераль кануны, 2013 нче елның 28 нче декабрендәге “Иминият пенсияләре турында” 400-ФК номерлы Федераль кануны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 нче елның 28 нче мартындагы “Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” 182 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 нче елның 17 нче октябрендәге “Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү хакында” 940 номерлы карары, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 4 нче сентябрендәге “Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында 43-102 номерлы карары белән расланган Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларга акчалата бүләкләү күләменә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1 нче кушымтаның 2 пунктында «4,65» саннарын " 6,72» саннарына алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 4 нче сентябрендәге “Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру турында” 43-102 номерлы карарының 13 нче кушымтасын “Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль

пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү тәртибе һәм шартлары тәртибен" яңа редакциядә бәян итәргә:

"1. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка, муниципаль хезмәткәргә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, пенсиягә өстәмә хокукы булганда, бер тапкыр акчалата бүләк түләнә.

Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка бер тапкыр бүләкләү биләгән вазыйфасы буенча билгеләнгән ун тапкыр айлык акчалата бүләк күләмендә түләнә.

Муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча эштән азат ителгән көнгә билгеләнә торган айлык акчалата керемнең биш тапкыр күләмендә түләнә, муниципаль хезмәт стажы 15 ел булганда һәм муниципаль хезмәтнең һәр киләсе тулы елы өчен өстәмә рәвештә 0,5 айлык акчалата керем, ул айлык акчалата керемнең ун күләменнән артмаска тиеш.

Муниципаль хезмәт стажы муниципаль вазыйфадан яки муниципаль хезмәттән азат ителгән көнгә билгеләнә.

2. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата тоту составына түбәндәгеләр кертелә: вазыйфаи оклад, класс чиннары өчен айлык өстәмә, муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү.

3. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турындагы карар тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә эштән азат итү турындагы карар белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

4. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү, пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көннән бер айдан да соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәрләр турыдан-туры эштән чыгар алдыннан хезмәт итә торган орган тарафыннан түләнә.

5. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк хезмәт кенәгәсендә билгеләнеп куела. Гражданга тиешле елларны эшләгән һәм аннан соң муниципаль хезмәт туктаткан өчен пенсиягә чыкканнан соң бер тапкыр бирелә торган бүләкләү яңадан муниципаль хезмәткә урнашкан очракта кабат түләнми.

6. Бер тапкыр бирелә торган бүләкне түләү җирле бюджет акчаларыннан гамәлгә ашырыла".

3. Әлеге карар 2018 нче елның 1 нче октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм үз көченә керә.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының рәсми сайтында" "Интернет" мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә ") http://pravo.tatarstan.ru., Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/. бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Шахмай
авыл җирлеге башлыгы

И.Г.Гаризов